Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге
Иске Йорт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

24 октябрь, 2022 ел

№ 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлегенең Иске Йорт торак пунктында 2022 елның 24 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 92 (туксанике).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 48 (кырык сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 45 (кырык биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 3 (өч).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2023 елда Иске Йорт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарын төзекләндерү

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Чыты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов